Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИШТУГАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы,
Иштуган т.ю.т.б., Үзәк урамы, 11 йорт
тел. 8 (84362) 4-20-37

Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИШТУГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан,
П.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, д. 11
тел. 8 (84362) 4-20-37

isht.sab@tatar.ru

2019 нчы елның 28 нче феврале № 10

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының
муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен
түләүгә киткән факттагы чыгымнары турында
квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару
тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131 — ФЗ номерлы Федераль законның 52 матдәсе һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә киткән факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибен расларга (кушымтада).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ishtugan адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы: Р. Ш. Галиахметов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитетының
2019 нчы елның 28 февралендә кабул ителгән
10 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәтләре өчен түләүгә киткән фактлагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару Тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1 «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә киткән чыгымнарының фактлагы күрсәткечләрен бастырып чыгару тәртибе (алга таба — Тәртип)

1.2. Тәртип Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә киткән фактлагы чыгымнары турында квартал саен белешмәләр тапшыру, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели (алга таба — мәгълүматлар).

## II. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә фактлагы чыгымнары турында мәгълүмат тапшыру тәртибе һәм составы

2.1. Мәгълүматлар квартал саен җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең уртача саны, шул исәптән хисап чорында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган Иштуган авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны турында, шулай ук хисап чорында хезмәт хакына исәпләнгән түләүләрне (акчалата эчтәлек) исәпкә алмыйча, хезмәт өчен түләү чыгымнарын тормышка ашыруга юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләре күләмен чагылдыралар.

2.2. Мәгълүматлар хисап чорыннан соң килүче айның 5 нче числосына кадәр әлеге Тәртипнең кушымтасы нигезендә бирелә.

2.3 Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма нигезендә мәгълүмат формалаштыра.

## III. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә киткән факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибе

3.1. Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан отчет чорыннан соң килүче айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча, мәгълүматларны раслау турында Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты карар проекты әзерләнә.

3.1.Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган белешмәләр квартал саен хисап артыннан килүче икенче айның соңгы числосына кадәр Иштуган авыл җирлеге сайтында бастырылырга тиеш.

Иштуган авыл җирлеге
җирле үзидарә органнарының
муниципаль хезмәткәрләре саны
һәм аларның хезмәтләре өчен түләүгә
киткән факттагы чыгымнары турында
квартал саен мәгълүматлар бастырып
чыгару тәртибенә кушымта

_____________20___ел хисап чорына

(беренче квартал, ярты ел. тугыз ай. ел)

Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында мәгълүматлар

| Хезмәткәрләр категориясе | Хисап чоры, хезмәткәрләр саны | Хисап чорына хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнар. (Мең сумнарда) |
| --- | --- | --- |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге муниципаль берәмлеге хезмәткәрләре | | |
| шул исәптән: муниципаль хезмәткәрләр | | |